РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

30 декабря 2022 — № 521

**Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетының 30.09.2021 елның №406 карары белән расланган җир кишәрлекләрен милеккә бирү хокукына ия затлар сыйфатында гражданнарга исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32, 32.1 статьяларына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокурорының 05.12.2022 ел. № 02-08-02/Прдп 319-22 протестына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесенең 30.09.2021 ел, № 406 карары белән расланган җир кишәрлекләрен милеккә бирү хокукы булган затлар буларак гражданнарга исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктның беренче абзацына сүзләр өстәргә:

«, әгәр мондый гражданнар Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлеге бирү көненә кадәр биш ел даими яшәп торалар һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торалар икән.»;

1.2. 1.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацы белән тулыландырырга:

«өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар, әгәр дә ата-ананың берсе генә яисә бердәнбер ата-ана Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында яшәгән булса, Татарстан Республикасы территориясендә биш ел дәвамында даими яшәү турындагы таләпкә туры килә дип санала.»;

1.3. 2.5.1 пунктны 9 һәм 10 пунктчалар һәм түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«9) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ буларак исәптә торуын раслаучы документ;

10) гариза бирүченең Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында даими яшәү

фактын билгеләү турында суд карары (гарызнамәче паспортында аның Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү турында биш ел дәвамында, җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр булган очракта).

Әлеге 9 пунктның күрсәтелгән Документ, гариза бирүче үз инициативасы буенча тәкъдим итмәсә, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә сорала.»;

1.4. 2.8.2.пунктның 2 пунктчасы түбәндәге эчтәлекле абзацын өстәргә:

«социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптән төшерү.»;

1.5. 2.8.2. пунктның 2 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«4) гражданнарның җир кишәрлеген сайлау процедурасында җир кишәрлеген сайлаудан өч тапкыр баш тартуы йә гражданнарның җир кишәрлеген сайлау процедурасына өч тапкыр килмәве, йә гражданнарның җир кишәрлеген сайлау процедурасында җир кишәрлеген сайлаудан баш тарту һәм аларның җир кишәрлеген сайлау процедурасына килмәү очраклары өчкә тигез булганда;»;

1.6. 3.3.1.1. пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Формат-логик тикшерү гариза бирүченең гаризаның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә башкарыла. Гаризаның электрон формасындагы бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган кырны ачыклаганда гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны электрон гариза формасында турыдан-туры мәгълүмати хәбәр аркылы бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының (http:pravo.ru.) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының (http://atnya.tatarstan.ru) рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисенә йөкләргә.

Җитәкчесе А.Ф.Каюмов